ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 1 өлештә:
2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели, шулай ук күрсәтелгән планны раслый;»;
түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:
«$2^1$) халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ стандартын раслый;»;
б) 2 пунктның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы тарафыннан раслана торган даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен билгелиләр;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 41-ТРЗ